РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.08.2026 Кукмара ш. № 451

Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категориядәге затларга ярдәм чаралары билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларында махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категориядәге затларга ярдәм итүнең бердәм база чаралары турында» 2026 елның 15 маендагы 327 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында һәм «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категориядәге затларга ярдәм чараларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 10 июлендәге 862 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категориядәге затларга ярдәм итүнең түбәндәге чараларын билгеләргә:

әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларның Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган муниципаль оешмаларына, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган күргәзмәләргә, мәгърифәтчелек, физкультура һәм спорт чараларына түләүсез йөрүе;

әлеге карарның 3 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән затларны гаиләнең яшәү урынына иң якын булган мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмасына, шул исәптән озайтылган көн төркеменә беренче чиратта кабул итү (шул исәптән бер белем бирү оешмасыннан икенчесенә күчергәндә);

әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларны әлеге карарның 3 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчаларында аталган мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына йөрүче затларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән тулысынча азат итү;

әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларны әлеге карарның 3 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчаларында аталган затларны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында озайтылган көн төркемнәрендә караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән тулысынча азат итү;

әлеге карарның 3 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән затларның башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча дәресләргә түләүсез йөрүе;

башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучы әлеге карарның 3 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән затларны түләүсез туклану белән тәэмин итү;

әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүче муниципаль маршрутларындагы гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында (таксидан тыш) түләүсез йөрү хокукын бирү.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ярдәм чаралары түбәндәгеләргә күрсәтелә дип билгеләргә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) (бурычларны үтәүгә ярдәм итүче (ярдәм иткән) затларга;

б) Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция (алга таба – кораллы провокация) уздырыла торган районнарга якын Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә кораллы провокация барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы бәреп керүне (алга таба – кораллы бәреп керүне) кире кагу бурычларын үтәүче (үтәгән) затларга;

в) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында 2014 елның 11 маеннан башлап хәрби хәрәкәтләрдә (алга таба – хәрби хәрәкәтләр) катнашкан затларга;

г) әлеге пунктның «а» – «в» пунктчаларында аталган затларның, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашуга (бурычларны үтәүгә), кораллы бәреп керүне кире кагу бурычларын үтәүгә бәйле, кораллы провокация барышында, хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булганнарның (вафат булганнарның), махсус хәрби операциядә катнашуга, күрсәтелгән бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә хәбәрсез югалган яисә билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган дип танылган затларның, шулай ук хәрби хезмәттән (хезмәттән, эштән) азат ителгәннән яки «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ирекле формированиеләрдән чыгарылганнан соң вафат булганнарның, әгәр андый затларның үлеме махсус

хәрби операциядә катнашу, күрсәтелгән бурычларны үтәү аркасында алган гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яки авыру нәтиҗәсендә килеп чыккан булса, гаилә әгъзаларына (алга таба – гаилә әгъзалары).

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында гаилә әгъзалары булып түбәндәгеләр танылалар:

а) ире (хатыны);

б) 18 яшькә җитмәгән, шул исәптән әлеге карарның 2 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында аталган затлар һәлак булганнан (үлгәннән) соң туган балалар һәм Россия Федерациясе Гаилә кодексының 48 статьясындагы 2 пункты нигезендә ата булу билгеләнгән балалар;

в) 18 яшькә җиткәнче инвалид булган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар;

г) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар;

д) әлеге карарның 2 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында аталган затлар белән бергә яшәүче йә бу затлар һәлак булган (үлгән) датага алар белән бергә яшәгән ата-аналар;

е) әлеге карарның 2 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында аталган затлар карамагындагы йә әлеге затлар һәлак булган (үлгән) датага шушы затлар карамагындагы затлар.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ярдәм чараларын әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга күрсәтү махсус хәрби операция тәмамланган елдан соң киләсе ел ахырына кадәр гамәлгә ашырыла, ә әлеге карарның 2 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында күрсәтелгән, махсус хәрби операциядә катнашуга (бурычларны үтәүгә), кораллы бәреп керүне кире кагу бурычларын үтәүгә, кораллы провокация барышында, хәрби хәрәкәтләр барышында алган гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яисә авыру нәтиҗәсендә билгеләнгән тәртиптә инвалид дип танылган затларга, аларның гаилә әгъзаларына һәм әлеге карарның 2 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында күрсәтелгән, махсус хәрби операциядә катнашуга, күрсәтелгән бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларына – вакыты чикләнми.

5. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ярдәм чараларын күрсәтү әлеге карарның 2 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында күрсәтелгән затлар тарафыннан хәрби хезмәт (хезмәт) узу турында контрактлар, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ирекле формированиеләрдә булу турында контрактлар, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килешүләр (башка хокук мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар), Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контрактлар (башка хокук мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар) төзү датасына һәм урынына бәйсез рәвештә, түбәндәгеләр тарафыннан бирелә торган документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

федераль дәүләт органнары тарафыннан – әлеге карарның 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән затларга карата;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан – әлеге карарның 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән затларга карата.

6. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы;

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 10 ноябрендәге 387 номерлы;

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 ноябрендәге 403 номерлы;

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 02 маендагы 259 номерлы;

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Баһамановага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**